СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2020 Әгерҗе шәһәре № 1-4

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы итеп билгеләп кую турында

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Вәлиев Азат Рөстәм улының «16 нчы бермандатлы Әгерҗе сайлау округы буенча «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты итеп сайлануга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең үз теләге белән эшләгән вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү турында» гаризасын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә (2020 елның 06 мартына үзгәрешләр һәм өстәмәләр исәпкә алып), Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы итеп, финанс һәм юридик, муниципаль норматив хокукый актларга һәм хокукый актларга имза салу хокукы белән, 2020 елның 14 сентябреннән контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен сайлау датасына кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Шәмсетдинов Илшат Илдус улын билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев